Республика Татарстан
**ГЛАВА МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ПОСЕЛОК ГОРОДСКОГО ТИПА ДЖАЛИЛЬ» САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
ул.Ахмадиева, д.26, п.Джалиль, 423368
Телефон: (85559) 31-0-97, 60-2-20, факс: 31-0-97
E-mail: POSSOVETD@mail.ru

Татарстан Республикасы
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ «ҖӘЛИЛ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОК» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
Ахмадиев урамы, 26 йорт, Җәлил поселогы, 423368
Телефон: (85559) 31-0-97, 60-2-20, факс: 31-0-97
E-mail: POSSOVETD@mail.ru

ОГРН 1021601312501 ИНН/КПП 1636001410/163601001

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР
08.11.2021 ел | №8

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Яңа Минзәләбаш авылында гражданнар җыенын 2022 елда үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча билгеләп кую турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы, Яңа Минзәләбаш авылы, Яңа Минзәләбаш урамы, 15 нче йорт адресы буенча мәчет бинасында 2021 елның 18 ноябрендә 14.00 сәгатьтә 2022 нче елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Минзәләбаш авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2022 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Яңа Минзәләбаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, I һәм II төркем инвалидларыннан, өлкән яшьтәге гражданнардан (80 яшьтән өлкәнрәк), җирлек территориясендә ел дәвамында яшәүче гражданнардан, авыр тормыш хәлендә калган гаилә әгъзаларыннан тыш, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне

башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?:

1) Яңа Минзәләбаш авылы зиратына керү юлларын төзекләндерү (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләү өчен түләү).

«РИЗА» ««КАРШЫ?»

3. Әлеге карарны «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән биш көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы»
«Җәлил шәһәр тибындагы поселогы»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р. Ә. Каримов